DOI: 10.26907/2311-2042-2024-23-2-94-103

# "THE LITERARY WORD" LED THE COMPETITION

**Marsel Khaernasovich Bakirov**,
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
bakirovvolk@mail.ru.

The article contains archival and personal materials related to the history of the national education at Kazan University: The wall newspaper "Edebi suz" ("The Literary Word"). The author examines the informative and communicative functions of the wall newspaper issued at the Tatar Department.

**Key words**: Kazan University, Tatar philology, Department of Tatar Language and Literature, wall newspaper "The Literary Word", history of periodicals

## Introduction

Wall newspapers are now perceived as an integral part of the Soviet era. Our contemporaries are looking with a smile at these coloured, typewritten pages on thick paper, perceiving them as one of the vivid attributes of a bygone era. At that time, for Soviet readers, wall newspapers were a popular form of self-expression and a publication equal to periodicals. Such newspapers were produced in every industrial or cultural organization, in every research centre or educational institution. They reflected the problems that were the focus of their collective attention. Their production was handled by an editor and members of the editorial board, elected by the staff, and performed as a type of social work.

For a long time, when studying sources related to periodicals, no attention was paid to identifying the educational phenomenon of wall newspapers. For example, in his book "Source Studies of the History of the USSR (Soviet Period)," M. Chernomorskiy included only one sentence about this important source: large-circulation newspapers were mainly born on the basis of wall newspapers [1]. The books, published during the perestroika period, also lack information about wall newspapers [2], [3], since no one was interested in looking for surviving copies of these newspapers. In recent years, materials are beginning to appear that indicate a revival of interest in the study of the wall newspapers' phenomenal role [4], [5], [6], [7]. In particular, V. Filatova notes the importance of wall newspapers in the lives of schoolchildren using the example of children's literature [7]. Among local authors, in one of her articles, M. Khabutdinova cites the students' recollections about how N. Isanbet and his students published handwritten magazines and literary wall newspapers [9]. The article by R. Dautova, T. Nagovitsyna and L. Gainullina is devoted to the history of the formation and transformation of the KSU mass-circulation newspaper "The Leninets", based on faculty wall newspapers. [10]

## Materials and methods

Today, celebrating the 80th anniversary of the Tatar Philology Department, Kazan Federal University, we recall with warmth the glorious events in the life of this Department, when the echoes of the era of national revival evoke a feeling of pride and spiritual pain for our people again and again. In this memorial note, I would like to tell you about the wall newspaper "The Literary Word", which at that time left an indelible mark on the life of the Tatar Language and Literature Department and on the hearts of its students, playing a major role in their fates.

## Discussion

The activities, aiming at the publication of wall newspapers in educational institutions as a mass phenomenon in Russia, had been in progress from the 1920s. At that time, a network of clubs, uniting young correspondents, was organized everywhere. Dozens of different newspapers and magazines were published in schools, secondary schools and creative associations. It was customary to place wall newspapers in display cases specially made of plywood. At that time, wall newspapers were aimed at educating the masses in the spirit of the dominant ideology of the party, they were a powerful tool of ideological management: "Wall newspapers appeared simultaneously with the workers' and village correspondents' movement as its strongholds. The CPSU considers the wall newspaper to be an important component of its ideological and organizational work. Party committees and bureaus directly influence the

activities of the editorial boards of wall newspapers" [11, p. 483].

Professional journalists always worked in the editorial office of the Kazan University's mass-circulation newspaper "The Leninets", and freelance authors also contributed their articles to the newspaper. The editorial office of the newspaper "The Leninets" held classes in journalism skills for students majoring in different fields. For many years, the staff of this university newspaper initiated wall newspaper competitions for all faculties [10, p. 25].

A creative society began to function at the Faculty of History and Philology of Kazan University from the first months of the Tatar Department's existence in 1944. It was engaged in organizing propaganda teams and producing the wall newspaper, "The Literary Word". In his novel "Let's Pray!", A. Gilyazov defines its significance as follows: "The Literary Gazette was produced on a regular basis, as long as a curtain it was: it became a forge of students' talents" [12, p. 201].

The newspaper production contributed to its creative growth and met the needs of its readers, proving the importance of the printed word. The writer Garif Akhunov writes in his memoirs about this period: "A literary society functioned at our Tatar Department. Its soul was the front-line soldiers Ibragim Nurullin, Makhmud Khusain and Rashad Gainanov. Rafak Timergalin was with them. I was also involved in the production of the newspaper "The Literary Word". Since I was fond of drawing from an early age, I made illustrations for the newspaper and sometimes contributed articles. At the same time, Yakhya Khalitov and I produced a faculty wall newspaper. Both Yakhya and I were its artists. The newspaper came out every month, and every month we created the headlines of articles for a several-meter long newspaper and drew caricatures... Yakhya was especially skilled in caricature. Looking at his drawings, the faculty history teacher, fell over laughing. Grigory Naumovich Wulfson was the editor-in-chief of the wall newspaper. Seeing that we were penniless, he filled his pockets with sweets and gingerbread and treated us to this sweet-stuff" (see: [13, p. 107].

Actually, I am a university veteran myself, having graduated from this department in 1956, and a little later, I taught in the same department for 50 years [15]. In 1989, the Faculty of Tatar Philology, History and Oriental Languages was created on the basis of this department, opened during the war [14]. Ten years had passed and the faculty was transformed into a department again; in 2011, after the merger of the departments of the Tatar language and literature with the similar ones from the Pedagogical Institute, it became the High School named after G. Tukay as a part of the Institute of Philology and Intercultural Communication of the University, preparing specialists in several fields.

My first acquaintance with the newspaper "The Literary Word" and participation in the newspaper production as an artist and member of the editorial board took place in 1951 when I entered the university. It was a time when the Department had a reputation as a national center for training qualified personnel, and was well-known to the entire Tatar world. To prove this, it is enough to say that the number of applicants willing to enter the Department annually reached 7-8 people per place. It was precisely due to this tough competition and the quality education that the graduates of the Tatar Philology Department became the golden pillars of our nation.

If, on the one hand, the secret of getting a good education is connected with the fact that the teachers of the Department, those who give lectures and conduct special courses, are amazingly highly qualified and well-educated mentors, on the other hand, it is connected with the opportunity to go on dialectological and folklore expeditions, to join literary and artistic (drama, choral) societies, to hold thematic conferences and scientific discussions, to participate in performances, discuss original works and the oeuvre of outstanding writers, to visit exhibitions and museums.

Undoubtedly, one of such important educational events at the time was the newspaper "The Literary Word", produced every two months. This newspaper, initiated by the first students of the Department, the front-line soldiers Makhmud Khusain, Akhat Nigmatullin, Ibragim Nurullin and those who followed them Garif Akhunov, Yakhya Khalitov, Rafak Timergalin, Zait Mazitov and Fazyl Fasiyev, for many years gave young talents the opportunity to demonstrate their creative talent and publish their first works written on a typewriter. Being a student, I worked as an artist of this wall newspaper, in fact keeping up the public work that G. Akhunov and Ya. Khalitov, engaged in the design of the newspaper, had carried out before me on their own initiative.

My close cooperation with the "The Literary Word" was resumed after I had returned to my alma mater, having worked for ten years in the Ufa

Regional Newspaper “Kyzyl tan” (“The Red Dawn”) published in the Tatar language. This time, as soon as I had passed the exams and begun my postgraduate course, I was appointed editor of this newspaper. When we took up this social work, “The Literary Word” took the third place among other wall newspapers published on a university scale. Our wall newspaper was inferior only to the newspaper “Leninskoye Znamya” (“The Lenin’s Banner”), the pride of the National History and Philology Faculty, and “Geograf” (“The Geografer”), the Russian-language newspaper of the Geographic Faculty.

I cannot help mentioning that, having received the editorial position and using my journalistic experience as well as attracting talented students, we quickly brought “The Literary Word” to the forefront. The size of the newspaper increased, it was 7-8 sheets of thick paper glued together, about 5-6 meters in length. And one more innovation: in each issue we introduced a literary and artistic supplement, “Allyuki”, consisting of samples of student creative work. Students, members of the literary society headed by the poet Zait Mazitov and later Muhammad Magdeev, published their works here. I remember the first story by Marsel Galiev, the first poems of such future writers as Rifa Rakhman, Dzhaudat Suleimanov, Gazinur Murat, Ramis Aymet, Rustem Sulti and Ilsiyar Ikhsanova, whose creative compositions were published in the “Allyuki” supplement. Roza Tufitulova, Zinnur Mansurov and Lyabib Leron, who later became editors-in-chief of various official organs, began their writing and journalistic careers here.

During the years of our editorship, Azat Ganiev, Mudarris Valeev, Makhtum Mustafin, Marsel Galiev, Zinnur Mansurov and Nazip Ismagilov made their unique contributions to the design of the newspaper and its fonts. Since the newspaper’s overall appearance depended heavily on the skill and resourcefulness of its artist, from time to time I drew a poster or created a general background associated with one or another important date and drew caricatures.

The Departments of Russian Philology and History, joining forces, repeatedly tried to bring the newspaper “The Leninskoye Znamya” to the first place. A year later, the charismatic Flera Safiullina was accepted to the editorial board by order of the party bureau, or rather, by her own request. Demonstrating extraordinary activity and exactingness, she strived to achieve this goal and show herself to advantage. I remember that the October issue, which was supposed to participate in the competition, was prepared without being shown to us. But Zinnur Mansurov, who was our artist at the time, made, as we were taught, a bas-relief image of the ship “Aurora”, the Winter Palace, the tower and bastions-fortresses of the Peter and Paul’s Fortress, and the rebellious masses against this background, cut out of gray velvet paper and pasted to the bottom of “The Literary Word”. This incredible picture shook the entire faculty to the core. Moreover, since the newspaper contained materials that were read in one breath, this time again we left no chance for our competitors.

Later, our newspaper also won the first place in the wall newspaper competition held in the Furriers’ Club, it was a competition for the entire Soviet District. A few years later, a citywide competition of all university wall newspapers was held in the gym of the Pedagogical Institute at Pole Ershov Street. Three issues of each institute newspaper were laid out on the floor in a large hall. All attention was drawn to the drawings made by the skillful hands of the students from the Construction Institute (KISC) and the Aviation Institute (KAI).

However, the members of the competition committee paid attention not only to the outward features of the newspapers, but also to their overall impression. They were also interested in the diversity of the presented materials and the thematic blocks they were subsumed into. Our “Literary Word” came first among numerous newspapers and was awarded a first-degree diploma.

Over time, student wall newspapers were replaced by large-circulation newspapers.

In 2003, Tatar students began publishing a newspaper called “Tereze” (“The Window”). The author of the idea, its founder and editor-in-chief was Lenar Sheikh. He both collected and edited materials contributed to the newspaper, prepared its layout and organized its distribution in educational institutions of Tatarstan and Bashkortostan. He raised the faculty publication of 50 copies to the level of a university newspaper with a circulation of 1000 copies. Along with the university bulletin, KSU students published their poems, stories and dramatic works in “The Tereze”. From 2010, Bulat Ibragimov was the editor-in-chief of “The Tereze”. In 2011, the last issue of the newspaper was published. As a result of the federalization of Kazan State University, the printed newspaper for Tatar students “Darelfon”

("The University") was created. Currently, the newspaper for Tatar students, "The Raushan" (editor Khalisa Shirman), is published and housed in a display case attached to the wall. This monthly newspaper, which is computer-printed, features creative works and articles by members of the literary society and other students.

### Main results

The wall newspaper was once a creative platform that helped students formulate and express their thoughts in writing, defend their point of view, respond to events happening in the world and develop qualities related to their future profession. Joint reading and discussion of published materials, participation in working on an article or first creative notes developed the students' worldview. They perceived publication or praise in the wall newspaper as a gift, regardless of the fire of criticism, seeking to correct shortcomings and improve their knowledge. In fact, the wall newspaper "The Literary Word" for more than half a century was a literary and pedagogical tool that artistically and aesthetically educated many Tatar students, helped them join mature national personnel, become talented writers and journalists in the field of education and culture.

**References**


1. Chernomorskii, M. N. (1966). *Istochnikovedenie istorii SSSR (sovetskii period)* [Source Studies of the History of the USSR (the Soviet Period)]. 343 p. Moscow, Vysshaya shkola. (In Russian)
2. Golikov, A. G. (2010). *Istochnikovedenie otechestvennoi istorii* [Source Studies of Russian History: A Textbook]. Ucheb. posobie. 4-e izd., ster. 464 p. Moscow, Akademiya. (In Russian)
3. *Istochnikovedenie: Teoriya. Istoriya. Metod. Istochniki rossiiskoi istorii : ucheb. posobie* (1998) [Source Studies: Theory. History. Method. Sources of Russian History: A Textbook]. I. N. Danilevskii, V. V. Kabanov, O. M. Medushevskaya, M. F. Rumyantseva; Ros. gos. gumanitar. un-t. 701 p. Moscow. (In Russian)
4. Veselovskii, A. G. (2013). *Osobennosti stennoi pechati v 1920-e gg. Tambovskie stengazety* [Peculiarities of Wall Press in the 1920s. Tambov Wall Newspapers]. Vestnik Tambovskogo gosudarstvennogo universiteta. Gumanitarnye nauki. Filologiya i iskusstvovedenie. Vyp. 2 (9118), pp. 180–189. (In Russian)
5. Skrebnev, V. A. (2014). *Stennaya pechat' Tambovskoi gubernii 1920-kh gg.: metody formirovaniya* [Wall Press of Tambov Province in the 1920s: Methods of Formation]. Al'manakh sovremennoi nauki i obrazovaniya. No. 12 (90), pp. 109–111. Tambov, Gramota. (In Russian)
6. Kuznetsov, V. V. (2009). *Stennaya pechat' Zapadnoi Sibiri kak istochnik po istorii sel'skokhozyaistvennykh reform serediny XX v.* [Wall Press of Western Siberia as a Source on the History of Agricultural Reforms of the Mid-20th Century]. Izvestiya Altaiskogo gosudarstvennogo universiteta. No. 4 (64). T. 4, pp. 135–137. Istoriya. (In Russian)
7. Safonov, D. A. (2015). *Stengazety kak ehlement sovetskoi deistvitel'nosti 1920-1930-kh gg.* [Wall Newspapers as an Element of Soviet Reality in the 1920s and 1930s]. Vestnik Orenburgskogo pedagogicheskogo universiteta. No. 1 (13), pp. 136–155. (In Russian)
8. Filatova, V. A. (2022). *Stengazeta kak variant shkol'noi pressy (na materiale detskoi literatury)* [Wall Newspaper as a Variant of School Press (based on children's literature)]. Materialy 1 Vserossiiskoi konferentsii: "Regional'naya zhurnalistika: kul'turnye kody, prostranstvo smyslov, poliehtnicheskii diskurs" ( YUFU, Rostov-na-Donu, 10-12 noyabrya 2022 g.). Taganrog, izdatel'stvo Yuzhnogo federal'nogo universiteta, pp. 242–244. (In Russian)
9. Khabutdinova, M. M. (2022). *Obraz Naki Isanbeta-pedagoga v vospominaniyakh ego uchenikova* [The Image of Naki Isanbet as a Teacher in the Memories of His Students]. Russian Linguistic Bulletin. No. 4 (32), pp. 1–7. URL: https://rulb.org/archive/4-32-2022-august/10.18454/RULB.2022.32.5 (accessed: 01.08.2024). (In Russian)
10. Dautova, R. V., Nagovitsina, T. A., Gainullina, L. F. (2023). *Transformatsiya vuzovskikh korporativnykh media* [Transformation of University Corporate Media]. Nauka. Obrazovanie. Sovremennost'. No. 1, pp. 24–27. (In Russian)
11. *Bol'shaya sovetskaya ehntsiklopediya* (1976) [Big Soviet Encyclopedia]. T. 24, 704 p. Moscow, Sovetskaya ehntsiklopediya. (In Russian)
12. Gilyazov A. (2013). *Jəgez, ber doga* [Let's Pray!]. 687 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
13. Iylmaz, G. M., Zavgarova, F. Kh., Khabutdinova, M. M. (2023). *Tvorcheskii portret fol'klorista Marselya Bakirova v zerkale ego lichnykh vospominanii i v otsenke sovremennikov* [Folklorist Marcel Bakirov's Creative Portrait in the Mirror of His Personal Memories and in the Assessment of His Contemporaries]. Tatarica. No. 2 (21), pp. 42–58. (In Russian)
14. Zamaletdinov, R. R., Khabutdinova, M. M. (2018). *Istoriya sozdaniya otdeleniya tatarskogo yazyka i literatury v Kazanskom universitete v vospominaniyakh prepodavatelei i pervykh studentov* [The Department of Tatar Language and Literature in Kazan University: The History of Its Creation in Memories of the Faculty Members and Alumni]. Tatarika. No. 1(10), pp. 91–113. (In Russian)

# БЕРЕНЧЕЛЕКНЕ ТОТКАН «ӘДӘБИ СҮЗ»

**Марсель Хәернас улы Бакиров,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
bakirovvolk@mail.ru

Мәкаләдә Казан университетында милли белем бирүнең үсеш тарихына, авторның «Әдәби сүз» стена газетасы белән бәйле истәлек материалларына һәм шәхси архивына нигезләнеп, күзәтү ясала. Узган гасырның 60–80 нче елларында татар бүлегендә чыккан стена газетасының мәгълүмати һәм коммуникатив функцияләре карала.

**Төп төшенчәләр:** Казан университеты, татар филологиясе, татар теле һәм әдәбияты бүлеге, «Әдәби сүз» стена газетасы, вакытлы матбугат тарихы

## Кереш

Бүгенге көндә стена газеталары совет чорының аерылгысыз өлеше буларак кабул ителә. Замандашларыбыз язу машинкасында басылган буяулы ватман битләренә узган чорның гаҗәеп бер атрибуты итеп карый. Үз вакытында стена газетасы – совет укучыларының фикерләрен, уй-кичерешләрен белдерүнең популяр формасы һәм вакытлы матбугат басмаларына тиңләштерелгән бер органы иде. Мондый газеталар һәрбер мәдәни оешмада, һәрбер фән үзәгендә, уку йортларында чыгарылып килде. Алар коллективларның көн үзәгендә торган проблемаларын чагылдыра иде. Стена газеталарын чыгару белән коллектив тарафыннан җәмәгать эше тәртибендә сайлап куелган редактор һәм редколлегия әгъзалары шөгыльләнде.

Вакытлы матбугатка караган чыганакларны өйрәнгәндә, озак еллар дәвамында стена газеталарының тәрбияви феноменын ачыклауга игътибар бирелмәде диярлек. Мәсәлән, М.Н. Черноморский «Источниковедение истории СССР (советский период)» исемле китабында бу мөһим чыганак турында нибары бер җөмлә белән әйтеп уза, күп тиражлы газеталар стена газеталары нигезендә туган дию белән чикләнә [1]. Үзгәрешләр чорында чыккан китапларда да стена газеталары турында мәгълүмат юк [2], [3], чөнки бу газеталар, кагыйдә буларак, бер данәдә генә булып, аларның сакланган нөсхәләрен эзләү белән шөгыльләнүче кеше булмаган. Соңгы елларда исә стена газеталарының феноменаль ролен өйрәнүгә игътибарның җанланып китүен раслый торган материаллар күренә башлады. [4], [5], [6], [7]. Аерым алганда, В.А. Филатова мәктәп укучылары тормышында стена газеталарының әһәмиятен балалар әдәбияты материалы мисалында язып чыкты [7]. Шулай ук М.М. Хәбетдинова бер мәкаләсендә Н. Исәнбәтнең үзенең укучылары белән кульъязма журналлар, әдәби стена газеталары чыгаруы турында шәкертләренең истәлекләрен мисал итеп китерә [9]. Р.В. Даутова, Т.А. Наговицина, Л.Ф. Гайнуллина мәкаләсе КДУда чыккан күп тиражлы «Ленинец» газетасының ничек итеп факультет стена газеталары җирлегендә оешуы һәм трансформацияләнүе тарихына багышлана [10].

## Материал һәм методлар

Бүген, университетта татар филологиясе бүлеге ачылуга 80 ел тулган көннәрдә, шушы бүлек тормышындагы мәртәбәле вакыйгалар күңелләрне җилкендереп искә төшә; милли җанланыш чорының кайтавазы булып, кавемебез өчен горурлану һәм җан атып яшәү тойгыларын кабат-кабат кузгатып, куәтләндереп җибәрә. Бу истәлек-язмамда шул чорда татар теле һәм әдәбияты бүлеге тормышында һәм анда белем алган студентларның күңелендә җуелмаслык эз калдырган яки бер өлешенең язмышында зур роль уйнаган стена газетасы «Әдәби сүз» турында сүз алып бармакчы булам.

## Фикер алышу

Россиядә уку йортларында стена газеталары чыгару эшчәнлегенең массакүләм күренеш буларак оешуы турында узган гасырның 20 нче елларыннан башлап сөйләргә була. Ул чагында юнкорларны (яшь хәбәрчеләрне) берләштергән түгәрәкләр челтәре оештырыла. Шуның нәтиҗәсе булып, мәктәпләрдә, урта һәм иҗади берләшмәләрдә йөзләрчә стена газеталары һәм журналлар барлыкка килә. Стена газеталарын фанерадан эшләнгән махсус витриналарда урнаштыру да гадәткә керә. Стена матбугаты

ул вакытта партия тарафыннан массаларны хакимлек итүче партия идеологиясе рухында тәрбияләү коралы вазифасын үти: «…Стенгазеты появились одновременно с рабселькоровским движением как его опорные пункты. КПСС рассматривает стенную печать как важный участок своей идеологической и организационной работы. Парткомитеты, бюро непосредственно направляют деятельность редколлегий стенгазет» [11, б. 483].

Казан университетының күп тираж белән чыга торган «Ленинец» газетасы редакциясендә һәрвакытта да профессиональ журналистлар эшләде, шулай ук газета битләрендә штаттан тыш авторларның материаллары басыла иде. «Ленинец» газетасы каршында төрле белгечләр булачак студентлар өчен журналистлык осталыгына өйрәтү дәресләре алып барды. Озак еллар буена университет газетасы коллективы барлык факультетларның стена матбугаты конкурсын оештыру эшенә дә җитәкчелек итте [10, б. 25].

Казан университетының тарих-филология факультетында 1944 елда татар бүлеге оешуның беренче айларыннан ук биредә иҗади түгәрәк эшли башлый, агитбригада чыгышлары оештырыла, «Әдәби сүз» дип аталган стена газетасы дөнья күрә. А. Гыйләҗев аның әһәмиятен «Йәгез, бер дога» романында болай дип бәяли: «Әдәби сүз» чаршау хәтле булып даими чыга, студентларның талантлылары шунда җорланалар» [12, б. 201]. Газета чыгару укучыларның иҗади үсешенә ярдәм итте, укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерде, басма сүзнең мөһимлеген исбатлады. Бу чор турында язучы Гариф Ахуновның истәлекләре сакланган: «Безнең татар бүлегендә әдәби түгәрәк эшли иде. Аның җаны булып, фронтовик Ибраһим ага Нуруллин, Мәхмүт Хөсәен, Рәшад Гайнанов санала иде. Рафак Тимергалин дә алар белән иде. «Әдәби сүз» стена газетасы эшчәнлегенә мине дә тарттылар. Кече яшьтән рәсем ясарга әвәс булганлыктан, газетаны мин бизим, мәкаләләр дә язгалый идем. Шул ук вакытта Яхъя Халитов белән без икәү факультетның стена газетасын да чыгара идек. Яхъя да, мин дә стена газетасының рәссамнары, ягъни бизәлеш мөхәррирләре идек. Ул ай саен чыга, һәм без ай саен берничә метр озынлыгындагы газетаның мәкалә башларын язабыз, карикатураларын ясыйбыз... Карикатурага Яхъя аеруча оста иде. Аның рәсемнәрен карагач, факультетта тарих фәнен укытучы Григорий Наумович Вульфсон егылаегыла көлә торган иде. Григорий Наумович Вульфсон стена газетасының баш редакторы иде, ул безнең акчага тилмергәнне күреп, кесәсенә кәнфит-прәннек тутырып килә торган иде» [13, б. 107].

Мин – 1956 елда шушы бүлекне тәмамлаган һәм шул ук бүлектә 50 ел буе укыткан вуз ветераны. Сугыш чорында Татар бүлеге нигезендә 1989 елда Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты оештырылды [14]. 2011 елда татар теле һәм әдәбияты кафедралары Казанның педагогика институты белән берләштерелгәч, Казан федераль университетының Л. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты составында берничә төрле белгеч әзерли торган Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе рәвешен алды.

«Әдәби сүз» газетасы белән беренче тапкыр танышуым һәм редколлегия әгъзасы-художник сыйфатында газетаны чыгаруда катнаша башлавым 1951 елда университетка укырга кергән чакка туры килә. Бүлегебезнең, милли кадрлар әзерләү үзәге буларак, исеме һәм шөһрәте бөтен татар дөньясын шаулаткан заман иде бу. Моңа ышану өчен бүлеккә укырга керергә ашкынган абитуриентлар санының ел да бер урынга 7-8 кешегә җиткәнлеген әйтү дә җитә торгандыр. Менә шундый зур конкурс, ягъни җиде кат иләк аша сөзелеп, конкурс аша үтеп кергәнгә һәм дә монда төпле белем алганга күрә дә, татар филологиясе бүлеген тәмамлап чыгучыларның милләтебезнең алтын баганалары булып китүе бик табигый.

Төпле белем алуның сере, бер яктан, лекцияләр укучы һәм махсус курслар уздыручы бүлек укытучыларының гаҗәеп әзерлекле һәм тирән гыйлемле остазлар булуы белән бәйләнгән булса, икенче яктан, бу диалектология һәм фольклор экспедицияләренә чыгып, халык белән аралашу, әдәбият һәм сәнгать (драма, хор) түгәрәкләрендә катнашу, тематик конференцияләр һәм фәнни бәхәсләр үткәрү, спектакльләрдә катнашып яки аерым әсәр һәм язучы иҗаты турында фикер алышу, истәлекле урыннарга һәм музейларга культпоходлар ясау кебек берсеннән-берсе файдалы чараларның үтә дә гамәли нәтиҗәсе белән аңлатыла.

Заманында ике айга бер мәртәбә чыгарылып торган «Әдәби сүз» газетасының да менә шундый саллы тәрбияви чараларның берсе булганлыгы шиксез. Бүлекнең беренче

студентлары булган фронтовиклар Мәхмүт Хөсәен, Әхәт Нигъмәтуллин, Ибраһим Нуруллин һәм алардан соң килгән Гариф Ахунов, Яхъя Халитов, Рафак Тимергалин, Зәет Мәҗитов, Фазыл Фәсиев кебек булачак олпат затларыбыз тарафыннан оештырылып һәм юлга салып җибәрелгән бу газета ничәмә еллар буена яшь талантларга иҗади чирканчык алырга мөмкинлек биргән, машинкада басылган өйрәнчек һәм иң тәүге әсәрләре белән башкаларны таныштырган. Студент чагында минем әлеге газетаны чыгаруда художник буларак катнашуым, асылда, миннән алда гына газетаны бизәү, рәсем ясау белән шөгыльләнгән Г. Ахунов һәм Я. Халитовның үзләре теләп алынган җәмәгать эшен эстафета рәвешендә дәвам итү булган.

Кабат «Әдәби сүз» белән тыгыз бәйләнешкә керүем, Уфада татар телендә чыга торган өлкә газетасы «Кызыл таң»да ун ел эшләп, альма-матерга әйләнеп кайтканнан соң булды. Бу юлы инде имтиханнар аша үтеп, аспирантурада укый башлау белән үк, мине ошбу газетаның мөхәррире итеп билгеләделәр. Без әлеге җәмәгать эшенә алынганда, «Әдәби сүз» университет күләмендә чыга торган башка стена газеталары арасында өченче урынны били иде. Ачыклап әйткәндә, үзебезнең тарих һәм филология факультетының горурлыгы булып саналган «Ленинское знамя» һәм география факультетының «Географ» исемле рус телендә чыгарылган газеталарыннан калыша иде.

Мактанып әйтүем түгел, мөхәррирлек вазифасы йөкләнгәч, журналистлык тәҗрибәсен файдаланып һәм, әлбәттә инде, талантлы студентларны җәлеп итеп, без «Әдәби сүз»не тиз арада беренче урынга чыгардык. Газетаның күләме зурайды, 7-8 ватман кәгазе бер-бер артлы ябыштырылып, буйга озынлыгы 5-6 метрга җитә торган иде. Һәм тагын бер яңалык: номер саен студентларның иҗат үрнәкләреннән торган «Әллүки» исемле әдәби-сәнгати кушымта биреп баруны гамәлгә керттек. Шагыйрь Зәет Мәҗитов һәм соңрак Мөхәммәт Мәһдиев алып барган әдәби түгәрәккә йөрүчеләрнең өйрәнчек әсәрләре шунда дөнья күрә иде. Хәтеремдә, Марсель Галиевнең беренче хикәясе, Рифә Рахман, Җәүдәт Сөләйманов, Газинур Морат, Рәмис Аймәт, Рөстәм Сүлти, Илсөяр Иксанова кебек булачак язучыларның тәүге шигырьләре «Әллүки» кушымтасында дөнья күрде. Соңыннан төрле рәсми органнарның баш редакторы булып киткән Роза Туфитуллова, Зиннур Мансуров, Ләбиб Лерон язучылык һәм журналистлык тәҗрибәсен башлап шушында алдылар.

Без мөхәррир булган елларда Азат Ганиев, Мөдәррис Вәлиев, Мәхтүм Мостафин, Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Нәҗип Исмәгыйлев кебек һәрьяктан да талантлы һәм киләчәктә зур юлга чыгачак студентлар бу газетаның бизәлешенә, шрифтларының матур итеп язылышына һәркайсы кабатланмас һәм үзенчәлекле өлеш керттеләр. Газетаның йөзе художникның осталыгына һәм тапкырлыгына нык бәйле булганлыктан, вакыт-вакыт мин теге яки бу зур датага бәйләнешле плакат яки гомуми җирлек булырдай рәсемнәрем белән, йә булмаса карикатуралар ясап, үзем дә катнаша торган идем.

Рус филологиясе һәм тарих бүлекләре, үзара берләшеп, «Ленинское знамя» газетасын кабат беренче урынга чыгарырга кат-кат тырышып карадылар. Бер елны хәтта мөхәррирлеккә партбюро кушуы буенча, дөресрәге, үзе теләп, Флёра Сафиуллина алынды. Гадәттән тыш активлыгын һәм таләпчәнлеген эшкә җигеп, шул максатка ирешергә, кемлеген күрсәтергә булды. Конкурста катнашырга тиешле октябрь ае номерын безгә күрсәтмичә әзерләүләре истә калган. Шул вакытта художник булган Зиннур Мансуров тарафыннан, без өйрәткәнчә, «Аврора» крейсеры, Кышкы сарай, Петропавловск крепосте манарасы, бастион-ныгытмаларының һәм шулар фонында восстаниегә күтәрелгән массаларның барельеф сурәте соры бәрхет кәгазьдән кисеп ясалды һәм буйдан-буйга сузып, «Әдәби сүз»нең аскы ягына ябыштырылды. Бу гаҗәеп отышлы күренеш бөтен факультетны шаккатырды. Өстәвенә, газета җырлап укыла торган материалларны эченә алганлыктан, бу юлы да көндәшләребезне өскә чыгартмадык.

Менә шулай яратып, йөрәк җылысын кушып чыгарганга күрә дә, арытаба безнең газета мехчылар клубында Совет районы күләмендә үткәрелгән стена газеталары ярышында шулай ук беренчелекне алды. Шуннан соң берничә ел үткәч, педагогия институтының Ершов урамында урнашкан спорт залында бөтен вуз стена газеталарының шәһәр күләмендәге конкурсы уздырылды. Зур зал идәненә һәр институт газетасының өчәр номеры җәеп салынган иде. Төзелеш институты (КИГС), авиация институты (КАИ)

студентлары тарафыннан чыгарылганнарын газеталарда оста куллар белән ясалган рәсемнәр барыбызның да игътибарын җәлеп итеп, үзенә тартып торды.

Ләкин комиссия әгъзалары газеталарның күзгә чалынып торган урыннарына гына түгел, ә аларның гомуми сыйфатына, бербөтен буларак нинди тәэсир калдыруларына игътибар иткәннәр. Шул исәптән материалларның төрлелеге һәм нинди тематик блокларга бүленүе белән дә кызыксынганнар. Безнең «Әдәби сүз» күп санлы газеталар арасында җиңеп чыгып, беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

Вакыт узу белән студентларның стена газеталарына алмашка күп тиражлы газеталар килде.

2003 елда татар студентлары «Тәрәзә» исемле газета чыгара башлады. Газетаның идея авторы, нигезләүчесе, баш мөхәррире Ленар Шәех булды. Ул газетага материалларны җыеп, аларны редакцияләп кенә калмый, аны үзе биткә дә сала торган иде, Татарстан, Башкортстан уку йортларына таратуны да ул оештырды. 50 данәле факультет басмасын ул 1000 данә тиражлы университет газетасы дәрәҗәсенә күтәрде. «Тәрәзә»дә университет хәбәрләре белән беррәттән, КДУ студентлары иҗат иткән шигырьләр, хикәяләр һәм драма әсәрләре дә басыла иде. 2010 елдан «Тәрәзә»нең баш мөхәррирен Булат Ибраһим алмаштырды. Ә инде 2011 елда газетаның соңгы саны чыкты. Казан дәүләт университеты федеральләшү нәтиҗәсендә, татар студентлары өчен басма «Дарелфөнүн» («Университет») газетасы оешты. Хәзерге вакытта исә татар студентлары өчен стенага беркетелгән витринага урнаштырыла торган «Раушан» исемле газета чыгарыла (мөхәррире Халисә Ширмән). Материаллары компьютерда басылып, аена бер мәртәбә чыга торган бу газетада әдәбият түгәрәгенә йөрүче һәм башка студентларның иҗат үрнәкләре һәм мәкаләләре урын ала.

## Төп нәтиҗәләр

Стена газетасы заманында студентларга үз фикереңне язмача формалаштырырга һәм башкаларга җиткерергә ярдәм итте, үз карашыңны якларга, дөньяда барган вакыйгаларга мөнәсәбәтеңне белдереп җавап бирергә, киләчәк эшеңә бәйле сыйфатларны үстерергә булышкан иҗади мәйдан булды. Анда басылган материалларны бергәләп уку һәм фикер алышу, мәкаләң яки тәүге иҗади язмаларың белән катнашу студентларның дөньяга карашын үстерде. Стена газетасында басылу яки макталуны алар бүләк итеп кабул иттеләр, тәнкыйть утына эләгү яки кимсетү дип бәяләмәделәр, кимчелекле якларын төзәтергә, белемнәрен камилләштерергә омтылдылар. Йомгаклап әйткәндә, исеме җисеменә туры килә торган «Әдәби сүз» стена газетасы ярты гасырдан артык татар студентларын художестволы-эстетик яктан тәрбияләгән, аларга мәгариф һәм культура өлкәсендә эшләячәк милли кадрлар һәм талантлы язучылар, журналистлар булып китәргә, олы юлга чыгарга ярдәм иткән әдәби-педагогик корал вазифасын үтәде.

**Әдәбият**


1. Черноморский М. Н. Источниковедение истории СССР (советский период). М.: Высшая школа, 1966. 343 с.
2. Голиков А. Г. Источниковедение отечественной истории : учеб. пособие. 4-е изд., стер. М.: Академия, 2010. 464 с.
3. Источниковедение: Теория. История. Метод. Источники российской истории : учеб. пособие / И. Н. Данилевский, В. В. Кабанов, О. М. Медушевская, М. Ф. Румянцева; Рос. гос. гуманитар. ун-т. М., 1998. 701 с.
4. Веселовский А. Г. Особенности стенной печати в 1920-е гг. Тамбовские стенгазеты // Вестник Тамбовского государственного университета. Гуманитарные науки. Филология и искусствоведение. 2013. Вып. 2 (9118). С. 180–189.
5. Скребнев В. А. Стенная печать Тамбовской губернии 1920-х гг.: методы формирования // Альманах современной науки и образования. Тамбов: Грамота, 2014. № 12 (90). С. 109–111.
6. Кузнецов В. В. Стенная печать Западной Сибири как источник по истории сельскохозяйственных реформ середины XX в. // Известия Алтайского государственного университета. 2009. № 4 (64). Т. 4. История. С. 135–137.
7. Сафонов Д.А. Стенгазеты как элемент советской действительности 1920-1930-х гг. // Вестник Оренбургского педагогического университета. 2015. №1 (13). С. 136–155.
8. Филатова В.А. Стенгазета как вариант школьной прессы (на материале детской литературы) // Материалы 1 Всероссийской конференции: «Региональная журналистика: культурные коды, пространство смыслов, полиэтнический дискурс» (ЮФУ, Ростов-на-Дону, 10-12 ноября 2022 г.). Таганрог: Издательство Южного федерального университета, 2022. С. 242–244.
9. Хабутдинова М. М. Образ Наки Исанбета-педагога в воспоминаниях его учеников // Russian Linguistic Bulletin. 2022. №4 (32). С. 1–7. URL: https://rulb.org/archive/4-32-2022-august/10.18454/

RULB.2022.32.5 (мөрәҗәгать итү вакыты 01.08.2024). – DOI: 10.18454/RULB.2022.32.5.

10. Даутова Р.В., Наговицина Т.А., Гайнуллина Л.Ф. Трансформация вузовских корпоративных медиа // Наука. Образование. Современность. 2023. №1. С. 24–27.

11. Большая советская энциклопедия. М.: Советская энциклопедия, 1976. Т. 24. 704 с.

12. Гыйләҗев А.М. Йәгез, бер дога. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 687 б.

13. Йылмаз Г.М., Завгарова Ф.Х., Хабутдинова М.М. // Г.М. Йылмаз, Ф.Х.Завгарова, М.М. Хабутдинова. Творческий портрет фольклориста Марселя Бакирова в зеркале его личных воспоминаний и в оценке современников // Tatarica. 2023. №2 (21). 42–58 б.

14. Замалетдинов Р.Р., Хабутдинова М.М. История создания отделения татарского языка и литературы в Казанском университете в воспоминаниях преподавателей и первых студентов // Татарика. 2018. №1(10). С. 91–113.

# «ӘДӘБИ СҮЗ» («ЛИТЕРАТУРНОЕ СЛОВО») – СТЕНГАЗЕТА-ПРИЗЕР

**Марсель Хаернасович Бакиров**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
bakirovvolk@mail.ru

В статье на основе личных воспоминаний реконструируется история стенгазеты «Әдәби сүз» («Литературное слово»). Выявлена информационная и коммуникативная роль стенгазеты, выпускавшейся на татарском отделении Казанского университета в 1960–80-е гг.

**Ключевые слова:** Казанский университет, татарская филология, отделение татарского языка и литературы, стенгазета «Әдәби сүз», история печати




1




2




КАЗАНСКИЙ ГОРКОМ ВЛКСМ

НАГРАЖДАЕТ

редколлегию газеты " Эдэби суз " ( редактор БАКИРОВ М. ) Казанского государственного университета, занявшую I место в городском смотре-конкурсе стенных газет высших учебных заведений, посвященного 30 - летию Победы советского народа в Великой Отечественной войне.

Секретарь Казанского ГК ВЛКСМ Ш. Агеев
6 июня 1975 года

3

**List of illustrations**

1. The headline of the wall newspaper "Adəbi suz" ("The Literary Word") of October 1994.
2. The funny picture of "The Teaching Staff of the Tatar Faculty, 1994."
3. The 1st Degree Diploma of the City Review of University Wall Newspapers timed to coincide with the 30th Anniversary of the Victory of the Soviet People in the Great Patriotic War.

**Иллюстрацияләр исемлеге**

1. «Әдәби сүз» стена газетасының 1994 елгы октябрь санының башисеме.
2. «Татар факультеты мөгаллимнәре коллективы, 1994» карикатурасы.
3. Югары уку йортларының стена газеталары арасында совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 30 ел тулуга багышлап үткәрелгән шәһәр смотрында җиңеп алган I дәрәҗә Диплом.

**Список иллюстраций**

1. Заголовок стенгазеты «Әдәби сүз» («Литературное слово») за октябрь 1994 г.
2. Карикатура «Коллектив преподавателей татфака, 1994».
3. Диплом I степени Городского смотра вузовских стенгазет к 30-летию Победы советского народа в Великой Отечественной войне.